КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 27 ноябрь г.Казань № 918

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе турында» 2012 ел, 2 октябрь, 818 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе тарафыннан башкарыла торган фәнни-гамәли тикшеренүләрне оештыру нәтиҗәлелеген күтәрү һәм яраштыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе турында» 2012 ел, 2 октябрь, 818 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 6 декабрь, 1061 нче; 2013 ел, 21 май, 335 нче; 2014 ел, 16 октябрь, 763 нче; 2014 ел, 31 декабрь, 1095 нче; 2015 ел, 25 сентябрь, 709 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе уставына (алга таба – Устав) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Уставка теркәлгән 2 нче кушымтада:

дүртенче абзацта «Перспективалы» сүзен «Гамәли» сүзенә алыштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Гаилә һәм демография үзәге.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\918.docx